Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Ямбакты авыл җирлеге Советы

КАРАР

21.07.2022 №63

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында ТР Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Ямбакты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Ямбакты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 2013 елның 28 февралендәге 47 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1. 2 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (туплау) капиталларында катнашу өлеше), санлы финанс активлары, санлы валютаны сатып алу буенча алыш-бирешләр кылган акчалар, муниципаль вазыйфа биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) соңгы өч елда гомуми кеременнән артып киткән очракта, һәм алыш-биреш кылуга алдагы өч елда алынган акча алу чыганаклары турында белешмәләр.».

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (htth:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Ямбакты авыл җирлеге башлыгы И. Ә. Галәветдинов